Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Трой-Урай авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

22 ноябрь 2024 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Троицкий Урай авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Трой-Урай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- урамдагы ачык яктырту челтәрләрен, трансформаторны һәм алар өчен бүтән подстанцияләрне, участокларны, тарату нокталарын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен бүтән җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, резидентларны су белән тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын тәртипкә китерү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү

- торак пункт территориясен яхшырту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Трой Урай авылы Прикамкая урамы, 9 йорт, Мәктәп урамы 13 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Гремячка авылы Александрова урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Мухаммаджанов Р.М.

Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы: Мухаммаджанов Р.М.